**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2024 елның «23» октябреннән №49-371

2024 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә дин һәм дәүләт-конфессиональ мөнәсәбәтләрнең торышы һәм 2025 елга бурычлар турында мәгълүмат

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе И.Х. Фәйзуллинның 2024 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә дин һәм дәүләт-конфессиональ мөнәсәбәтләрнең торышы һәм 2025 елга бурычлар турында мәгълүматын тыңлап, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә дин һәм дәүләт-конфессиональ мөнәсәбәтләр торышы һәм 2025 елга бурычлар турында мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советында конфессияара мөнәсәбәтләр буенча җаваплы И.Х.Фәйзуллинга:

- ел саен үткәрелә торган гомуми җыелышларда мәхәллә кешеләре арасында һәм төрле милләт вәкилләре арасында законлылыкны саклауга һәм конфликтларны булдырмауга юнәлдерелгән аңлату-профилактика эшләре уздырырга;

- җирле дини оешмаларның социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыру эшчәнлегенә ярдәм итү өчен грантлар һәм субсидияләр алу буенча республика конкурсларында катнашуларын активлаштырырга.

3. Җирле дини оешмаларга һәм берләшмәләргә тәкъдим итәргә:

- дини объектларны дәүләт теркәвенә алу буенча эшне дәвам итәргә;

- рухи семинариядә һәм мәдрәсәдә укырга җибәрү өчен кандидатлар сайлап алу эшен оештырырга;

- аерылышуларны булдырмау максатларында никахларны һәм гаилә кыйммәтләрен саклау буенча яшь гаиләләр белән максатчан эш алып барырга;

- районның һәм җирлекләрнең иҗтимагый тормышында актив катнашырга.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының социаль, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте буенча депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов